| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**16.06.2023** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 1790** |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 10 гыйнварындагы 2 номерлы карары белән расланган, муниципаль милектәге җир кишәрлеген милеккә, арендага, даими (сроксыз) файдалануга, түләүсез файдалануга торглар үткәрмичә генә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы Федераль закон, РФ Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы карары, 2022 елның 14 июлендәге «Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминләштерү фонды турында» 236-ФЗ номерлы Федераль закон, 2022 елның 14 июлендәге«Гражданнар тарафыннан бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм үз ихтыяҗлары өчен һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 312-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 10 гыйнварындагы 2 номерлы карары белән расланган, муниципаль милектәге җир кишәрлеген милеккә, арендага, даими (сроксыз) файдалануга, түләүсез файдалануга торглар үткәрмичә генә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба - административ регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Административ регламентның 3.3.2.1 пунктындагы унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мөрәҗәгать итүче тарафыннан рәсми мөрәҗәгатьнең электрон формасында һәр юлын тутыру процессында формалаштырылган рәсми мөрәҗәгатьне формаль-логик тикшерү, орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, Бердәм порталда автомат рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал тарафыннан рәсми мөрәҗәгатьнең электрон формасында дөрес тутырылмаган юллары ачыкланганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры рәсми мөрәҗәгатьнең электрон формасында мәгълүмати хәбәр аша җиткерелә».

1.2. Административ регламентның 2.6.1 пунктындагы 22 пунктчасында «Россия Федерациясе Пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясенең Татарстан Республикасы буенча пенсия һәм социаль иминләштерү фонды» сүзләренә алмаштырырга.

1.3. Административ регламентның 2.8.2 пунктындагы 13 пунктчасында «бакчачылыкны» сүзен «гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык алып барулары» сүзләренә алмаштырырга.

1.4. Административ регламентның 2.7.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле пунктча белән тулыландырырга:

«9) гаризада һәм аңа кушылып бирелгән документларда каршылыклы белешмәләр булу».

2. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә . әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.В. Старостин